**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 4 апрелендәге 1029 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2014 елның 30 декабрендәге 7660 номерлы**
**«Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкалар булдыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре территориясендә бердәм парковка киңлеге эшчәнлеген тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешәр кертү хакында»гы федераль законнарга, 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы законына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 18 апрелендәге 2096 номерлы «Казан шәһәрендә парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм алардан файдалану, шул исәптән түләүле нигездә файдалану тәртибе турында»гы карарына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 30 декабрендәге 7660 номерлы «Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкалар булдыру турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 16 февралендәге 734 номерлы, 2015 елның 4 июнендәге 2284 номерлы, 2015 елның 2 октябрендәге 3598 номерлы, 2016 елның 22 гыйнварындагы 148 номерлы, 2016 елның 4 апрелендәге 1311 номерлы, 2016 елның 27 апрелендәге 1806 номерлы, 2016 елның 29 июнендәге 2621 номерлы, 2016 елның 17 октябрендәге 4156 номерлы, 2016 елның 2 декабрендәге 4908 номерлы, 2017 елның 31 гыйнварындагы 162 номерлы, 2017 елның 23 июнендәге 2270 номерлы, 2017 елның 24 октябрендәге 4269 номерлы, 2017 елның 4 декабрендәге 4964 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 3657 номерлы, 2018 елның 18 июлендәге 4032 номерлы, 2018 елның 18 сентябрендәге 4987 номерлы, 2018 елның 4 декабрендәге 6132 номерлы, 2019 елның 16 апрелендәге 1404 номерлы, 2019 елның 26 июлендәге

2714 номерлы, 2019 елның 19 сентябрендәге 3326 номерлы, 2019 елның 13 ноябрендәге 4029 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 2918 номерлы, 2020 елның 26 ноябрендәге 3464 номерлы, 2021 елның 28 гыйнварындагы 199 номерлы, 2021 елның 18 мартындагы 635 номерлы, 2021 елның 5 маендагы 1121 номерлы, 2021 елның 5 июлендәге 1648 номерлы, 2021 елның 28 июлендәге 1860 номерлы, 2021 елның 9 сентябрендәге 2260 номерлы, 2021 елның 21 октябрендәге 2736 номерлы, 2021 елның 11 ноябрендәге 2960 номерлы, 2021 елның 22 декабрендәге 3433 номерлы, 2022 елның 2 февралендәге 331 номерлы, 2022 елның 17 июнендәге 1856 номерлы, 2022 елның 6 июлендәге 2135 номерлы, 2022 елның 21 октябрендәге 3601 номерлы, 2023 елның 16 гыйнварындагы 77 номерлы, 2023 елның 13 июлендәге 1972 номерлы, 2023 елның 2 октябрендәге 2907 номерлы, 2023 елның 1 декабрендәге 3788 номерлы, 2023 елның 29 декабрендәге 4418 номерлы, 2024 елның 13 февралендәге 494 номерлы, 2024 елның 7 маендагы 1945 номерлы, 2024 елның 1 августындагы 3221 номерлы, 2024 елның 20 сентябрендәге 3991 номерлы, 2024 елның 2 ноябрендәге 4626 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. 1 номерлы кушымтада:

1.1.1.1. 1, 2, 3, 9, 20, 27, 51, 54, 55, 66, 69, 70, 71, 74, 75, 76, 77, 78, 80, 83, 84, 85, 86, 88, 89, 94, 95, 100, 108, 109, 115, 117, 125, 141, 157, 171, 198, 209, 210, 211 юлларны әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә;

1.1.1.2. 37 юлны төшереп калдырырга;

1.1.1.3. «БАРЛЫГЫ» юлында «10867» санын «10819» санына алмаштырырга;

1.1.2. 3 номерлы кушымтада:

1.1.2.1. 2.1.3 пунктны «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмау» сүзләреннән соң «, шулай ук Казан шәһәренең электромобильләрне парковкага куюга рөхсәтләр реестрына электромобильне парковкага куюга рөхсәт бирү турында язма кертү» сүзләрен өстәргә;

1.1.2.2. 2.2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.1.2.3. 2.3.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Кулланучы мобиль кушымта ярдәмендә яки гражданинның шәхси кабинетында яисә parkingkzn.ru веб-порталында үз инициативасы белән түбәндәге параметрларны үзгәртә ала: дәүләт теркәве билгесе һәм парковка

зонасы номеры, ләкин транспорт чарасын Казан шәһәренең түләүле муниципаль парковкасындагы парковка урынына урнаштырган көннең 23 сәгате 59 минутына кадәр бер тапкырдан артык түгел.

Дәүләт теркәве билгесен һәм (яки) парковка зонасы номерын үзгәрткән очракта, парковка сессиясен башлау һәм (яки) тәгәлләү вакытына төзәтмәләр кертү мөмкин түгел.

Дәүләт теркәве билгесенә һәм (яки) парковка зонасы номерына төзәтмәләрне парковка сессиясе тәгәлләнгәннән соң гына кертергә мөмкин.

Тәгәлләнгән парковка сессиясенең югарыда күрсәтелгән параметрларын үзгәртү кулланучыга мобиль кушымта һәм parkingkzn.ru веб-порталы ярдәмендә төзәтмәләр кертү мөмкинлеге бирә торган өстәмә функция булып тора һәм транспорт чарасын түләүле шәһәр парковкасына куйган өчен гамәлдәге законнар нигезендә административ җаваплылыкка тартуны күз алдында тоткан түләмәү булып саналмый»;

1.1.2.4. түбәндәге эчтәлекле 2.3.5 пункт белән тулыландырырга:

«2.3.5. түләү:

- http://pay.parkingkzn.ru сайты аша, инструкция буенча;

- мәгълүмат такталарындагы QR-код ярдәмендә, http://parkingkzn.ru сайтында «Теркәлмичә ТИЗ ТҮЛӘҮ» төймәсе ярдәмендә;

- «Казан паркингы» телеграм-каналында (https://t.me/parkingkzn) беркетелгән «тиз түләү» хәбәре аша.

http://pay.parkingkzn.ru сайтының ачылган тәрәзәсендә өч актив юлны (зона номерын, А000АА116 форматында транспорт чарасы номерын, парковкага кую вакытын) тутырырга һәм банк картасы мәгълүматларын кертергә кирәк.

Акча банк картасыннан салдырыла. Парковка сессиясен туктату һәм озайту каралмаган. Минималь парковка сессиясе 30 минутны тәшкил итә, аннан соңгы тарификация – 15 минут»;

1.1.2.5. 2.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.4. Транспорт чарасын түләүле муниципаль парковкадагы парковка урынына урнаштыручы зат, транспорт чарасын бушлай кую очракларыннан кала, парковка урынына керү вакытыннан алып 15 минуттан да соңга калмыйча, ә 4 номерлы кушымта нигезендә дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау системаларының медицина оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем бирә торган гомуми белем бирү оешмалары урнашкан биналар һәм корылмалар янындагы парковкалар территорияләрендә 30 минуттан да соңга калмыйча,

түләүле шәһәр парковкасына транспорт чарасын куйган өчен әлеге Кагыйдәләрнең 2.3.1-2.3.5 пунктларында күрсәтелгән түләү ысулларының берсен кулланып, автомобиль кую сессиясен башларга тиеш»;

1.1.3. әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә редакцияләнгән карарга 4 номерлы кушымта белән тулыландырырга;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) юл хәрәкәтендә катнашучыларга муниципаль парковкалардан файдалану кагыйдәләрендәге үзгәрешләр турында массакүләм мәгълүмат чаралары, социаль медиаресурслар аша хәбәр итәргә **тәкъдим итәм**.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 4 апрелендәге
1029 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәрендә җирле әһәмияттәге
гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында
түләүле муниципаль парковкалар
(парковка урыннары) реестры**

| № т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Парковка урыннар-ыннан 1 сәгать файдаланган өчен түләү күләме |
|---|---|---|---|
| «1 | Профсоюз урамы (урамның так ягы, Профсоюз урамындагы 6 номерлы йорт каршында) | 5 | 100 сум |
| 2 | Профсоюз урамы (урамның җөп ягы, Чернышевский урамы белән кисешкән урыннан Бауман урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 61 | 100 сум |
| 3 | Пушкин урамы (урамның так ягы, Профессор Нужин урамы белән кисешкән урыннан Профсоюз урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 19 | 100 сум» |
| «9 | Париж Коммунасы урамы (урамның ике ягы да, Сул як Болак урамы белән кисешкән урыннан Нариманов урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 120 | 70 сум» |
| «20 | Киров тыкрыгы (урамның так ягы, Киров тыкрыгындагы 4 номерлы йорттан Сул як Болак урамына кадәр; урамның җөп | 33 | 70 сум» |

| №<br>т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Парковка урыннар-ыннан 1 сәгать файдаланган өчен түләү күләме |
|---|---|---|---|
| | ягы Мәскәү урамыннан Сул як Болак урамына кадәр) | | |
| «27 | Татарстан урамы (урамның җөп ягы, Татарстан урамындагы 16 номерлы йорттан 20 номерлы йортка кадәр) | 13 | 70 сум» |
| «51 | Спартак урамы (урамның җөп ягы, А.Айдинов урамы белән кисешкән урыннан Һ.Такташ урамы белән кисешкән урынга кадәр; урамның так ягы, Һ.Такташ урамы белән кисешкән урыннан Спартак урамындагы 21 номерлы йортка кадәр) | 90 | 100 сум» |
| «54 | Некрасов урамы (урамның так ягы, Кочетов тыкрыгы белән кисешкән урыннан Пушкин урамы белән кисешкән урынга кадәр, Маяковский урамы белән кисешкән урыннан Кочетов тыкрыгы белән кисешкән урынга кадәр) | 74 | 70 сум |
| 55 | Пушкин урамы (Пушкин урамындагы 10 номерлы йорт янында) | 10 | 70 сум» |
| «66 | Һ.Такташ урамы (урамның ике ягы да, М.Сәлимҗанов урамы белән кисешкән урыннан Спартак урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 90 | 100 сум» |
| «69 | А.Айдинов урамы (урамның җөп ягы, Островский урамы белән кисешкән урыннан Тихомирнов урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 22 | 70 сум |
| 70 | Петербург урамы (урамның ике ягы да, Т.Миңнуллин урамы белән кисешкән | 160 | 70 сум |

| № т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Парковка урыннар-ыннан 1 сәгать файдаланган өчен түләү күләме |
|---|---|---|---|
| | урыннан А.Айдинов урамы белән кисешкән урынга кадәр) | | |
| 71 | Малая Красная урамы (урамның җөп ягы, Большая Красная урамы белән кисешкән урыннан Адамюк урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 40 | 100 сум» |
| «74 | Т.Миңнуллин урамы (урамның так ягы, Островский урамы белән кисешкән урыннан Петербург урамына кадәр) | 23 | 70 сум |
| 75 | Петербург урамы (урамның ике ягы да, Т.Миңнуллин урамы белән кисешкән урыннан Суконная урамына кадәр) | 74 | 70 сум |
| 76 | Профсоюз урамы (урамның җөп ягы, Профсоюз урамындагы 44 номерлы йорттан 38 номерлы йортка кадәр) | 5 | 100 сум |
| 77 | Профсоюз урамы (урамның җөп ягы, Профсоюз урамындагы 36 номерлы йорттан 32 номерлы йортка кадәр) | 10 | 100 сум |
| 78 | Профсоюз урамы (урамның так ягы, Бауман урамындагы 9а номерлы йорт янында) | 25 | 100 сум» |
| «80 | Уң як Болак урамы (урамның так ягы, Уң як Болак урамындагы 47 номерлы йорттан Астрономия урамы белән кисешкән урынга кадәр; Астрономия урамы белән кисешкән урыннан Уң як Болак урамындагы 41 номерлы йортка кадәр; Уң як Болак урамындагы 37 номерлы йорттан М.Җәлил урамы белән кисешкән урынга кадәр; Уң як | 44 | 70 сум» |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| № т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Парковка урыннар-ыннан 1 сәгать файдаланган өчен түләү күләме |
|---|---|---|---|
| | Болак урамындагы 13 номерлы йорт янында) | | |
| «83 | Япеев урамы (урамның так ягы, Нагорная урамы белән кисешкән урыннан Большая Красная урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 45 | 70 сум |
| 84 | Бехтерев урамы (урамның җөп ягы, Япеев урамы белән кисешкән урыннан К.Фукс урамы белән кисешкән урынга кадәр, урамның так ягы, Бехтерев урамындагы 9 номерлы йорт каршында) | 42 | 70 сум |
| 85 | К.Фукс урамы (урамның ике ягы да, Большая Красная урамы белән кисешкән урыннан Бехтерев урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 22 | 70 сум |
| 86 | К.Нәҗми урамы (урамның җөп ягы, Уң як Болак урамы белән кисешкән урыннан Островский урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 10 | 100 сум» |
| «88 | Галактионов урамы (урамның так ягы, Пушкин урамы белән кисешкән урыннан Горький урамы белән кисешкән урынга кадәр, урамның җөп ягы, Пушкин урамы белән кисешкән урыннан Галактионов урамындагы 12 номерлы йортка кадәр) | 50 | 70 сум |
| 89 | М.Җәлил урамы (урамның җөп ягы, Уң як Болак урамы белән кисешкән урыннан Островский урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 5 | 100 сум» |

| № т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Парковка урыннар-ыннан 1 сәгать файдаланган өчен түләү күләме |
|---|---|---|---|
| «94 | Ш.Мәрҗани урамы (урамның так ягы, Татарстан урамы белән кисешкән урыннан КСКА урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 66 | 70 сум |
| 95 | Әхтәмов урамы (урамның ике ягы да, Г.Тукай урамы белән кисешкән урыннан Ш.Мәрҗани урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 7 | 30 сум» |
| «100 | А.Айдинов урамы (Спартак урамы белән кисешкән урыннан М.Сәлимҗанов урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 10 | 100 сум» |
| «108 | Әхтәмов урамы (урамның так ягы, С.Садыйкова урамы белән кисешкән урыннан Г.Тукай урамына кадәр) | 13 | 30 сум |
| 109 | Әхтәмов урамы (урамның так ягы, Әхтәмов урамындагы 19 номерлы йорт янында, урамның җөп ягы, С.Садыйкова урамы белән кисешкән урыннан Әхтәмов урамындагы 26А номерлы йортка кадәр) | 26 | 30 сум» |
| «115 | Р.Яхин урамы (урамның так ягы, Г.Исхакый урамы белән кисешкән урыннан Мәскәү урамы белән кисешкән урынга кадәр; урамның җөп ягы, Мәскәү урамы белән кисешкән урыннан, Мәскәү урамындагы 2А номерлы йорт янында) | 29 | 70 сум» |
| «117 | Һ.Такташ урамы (урамның ике ягы да, Спартак урамы белән кисешкән урыннан Островский урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 40 | 100 сум» |

| №<br>т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Парковка урыннар-ыннан 1 сәгать файдаланган өчен түләү күләме |
|---|---|---|---|
| «125 | Чистай урамы (җирле юл, урамның так ягы, Чистай урамындагы 5, 7, 11, 15, 19 номерлы йортлар буйлап) | 236 | 50 сум» |
| «141 | Толстой урамы (Большая Красная урамындагы 67 номерлы йорт буйлап) | 16 | 30 сум» |
| «157 | Сул як Болак урамы (урамның җөп ягы, Г.Камал урамы белән кисешкән урыннан Париж Коммунасы урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 6 | 70 сум» |
| «171 | Чернышевский урамы (урамның так ягы, Мәскәү урамы белән кисешкән урыннан Сул як Болак урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 13 | 70 сум» |
| «198 | З.Солтан урамы (урамның җөп ягы, Ш.Мәрҗани урамы белән кисешкән урыннан З.Солтан урамындагы 6 номерлы йортка кадәр) | 8 | 70 сум» |
| «209 | Чернышевский урамы (Сул як Болак урамындагы 24/20 номерлы йорт янындагы территория) | 17 | 50 сум |
| 210 | Һ.Такташ урамы (урамның ике ягы да, М.Сәлимҗанов урамы белән кисешкән урыннан Н.Назарбаев урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 98 | 50 сум |
| 211 | Петербург урамы (урамның ике ягы да, Суконная урамы белән кисешкән урыннан Н.Назарбаев урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 58 | 50 сум» |

Документ создан в электронной форме. № 50258-ПСП от 28.04.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 11 из 17. Страница создана: 28.04.2025 12:18
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 4 апрелендәге
1029 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында түләүле муниципаль парковкалар (парковка урыннары), дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау системаларының медицина оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем бирә торган гомуми белем бирү оешмалары урнашкан биналар һәм корылмалар янындагы парковкалар исемлеге**

| № т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Социаль объект атамасы |
|---|---|---|---|
| 1 | Париж Коммунасы урамы (урамның так ягы, Нариманов урамы белән кисешкән урыннан Г.Тукай урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 19 | «К.Насыйри исемендәге аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 80 номерлы татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе |
| 2 | Мөштәри урамы (урамның так ягы, Большая Красная урамы белән кисешкән урыннан К.Маркс урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 10 | «Катнаш төрдәге 312 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 3 | Толстой урамы (урамның җөп ягы, Бутлеров урамы белән кисешкән урыннан Щапов урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 19 | В.С.Груздев исемендәге бала тудыру йорты, «Медицина университеты клиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе |

| №<br>т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Социаль объект атамасы |
|---|---|---|---|
| 4 | Лейтенант Шмидт урамы (урамның так ягы, Вишневский урамы белән кисешкән урыннан Чехов урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 24 | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе клиникасы, Комплекслы диагностика һәм дәвалау үзәге |
| 5 | Жуковский урамы (урамның так ягы, Адамюк урамы белән кисешкән урыннан Большая Красная урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 20 | «Советлар Союзы Герое А.С.Үмәркин исемендәге 116 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе |
| 6 | Сафьян урамы (урамның так ягы, Сафьян урамындагы 2 номерлы йорт янында килеп туктау өчен махсус киңәйтелгән урын) | 8 | «12 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе |
| 7 | Япеев урамы (урамның так ягы, Нагорная урамы белән кисешкән урыннан Бехтерев урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 15 | «Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 39 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе |
| 8 | Бехтерев урамы (урамның җөп ягы, Япеев урамы белән кисешкән урыннан, Бехтерев урамындагы 4А, 6 номерлы йортлар буйлап) | 15 | «Катнаш төрдәге 49 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |

| №<br>т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Социаль объект атамасы |
|---|---|---|---|
| 9 | Спартак урамы (урамның җөп ягы, Т.Миңнуллин урамындагы 8А номерлы йорт буйлап) | 10 | «Татар телендә тәрбия һәм белем бирә торган катнаш төрдәге 24 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 10 | Лейтенант Шмидт урамы (урамның җөп ягы, Әбҗәлилов урамы белән кисешкән урыннан Ветеринария урамы белән кисешкән урынга кадәр; урамның так ягы, Ветеринария урамы белән кисешкән урыннан Товарищеская урамы белән кисешкән урынга кадәр, урамның җөп ягы, Товарищеская урамы белән кисешкән урыннан Зинин урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 56 | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе клиникасы, «Катнаш төрдәге 312 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, «255 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 11 | Лейтенант Шмидт урамы (урамның җөп ягы, Лейтенант Шмидт урамындагы 30 номерлы йорт буйлап) | 6 | «2 номерлы балалар поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе |
| 12 | Товарищеская урамы (урамның җөп ягы, Лейтенант Шмидт урамы белән кисешкән урыннан Достоевский урамы | 12 | «28 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе |

| №<br>т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Социаль объект атамасы |
|---|---|---|---|
| | белән кисешкән урынга кадәр) | | |
| 13 | Ф.Кәрим урамы (урамның җөп ягы, Г.Тукай урамы белән кисешкән урыннан К.Насыйри урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 6 | «7 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе |
| 14 | Бондаренко урамы (урамның җөп ягы, С.Хәким урамы белән кисешкән урыннан Бондаренко урамындагы 30 номерлы йортка кадәр) | 21 | Казан шәһәренең «“Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл” полилингваль комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе |
| 15 | Нигъмәтуллин урамы (урамның җөп ягы, С.Хәким урамы белән кисешкән урыннан Чистай урамы белән кисешкән урынга кадәр, С.Хәким урамы белән кисешкән урыннан, Нигъмәтуллин урамындагы 1 номерлы йорт буйлап) | 37 | «107 номерлы “Открытие” гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «Катнаш төрдәге 192 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, «Катнаш төрдәге 117 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 16 | Качалов урамы (урамның так ягы, Газ урамы белән кисешкән урыннан Шаляпин урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 17 | «Р.Г.Хәсәнова исемендәге аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 82 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» |

Документ создан в электронной форме. № 50258-ПСП от 28.04.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 15 из 17. Страница создана: 28.04.2025 12:18
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| № т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Социаль объект атамасы |
|---|---|---|---|
| | | | муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «Катнаш төрдәге 160 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 17 | Шаляпин урамы (урамның җөп ягы, 1 нче Бөгелмә урамы белән кисешкән урыннан Ботаника урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 19 | «Катнаш төрдәге 156 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 18 | Толстой урамы (Большая Красная урамындагы 67 номерлы йорт буйлап) | 14 | Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү институты, йогышлы-аллергик авырулар поликлиникасы |
| 19 | Четаев урамы (урамның җөп ягы, Бондаренко урамы белән кисешкән урыннан Әпсәләмов урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 28 | «179 номерлы гимназия – мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «Катнаш төрдәге 151 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе |
| 20 | Н.Ершов урамы белән кисешкән урыннан Вишневский урамына чыгу юлы | 15 | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина-санитария часте |

| № т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Социаль объект атамасы |
|---|---|---|---|
| 21 | Достоевский урамы (урамның так ягы, Вишневский урамы белән кисешкән урыннан Чехов урамы белән кисешкән урынга кадәр) | 10 | «96 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе |
| 22 | Ә.Терегулов урамы (урамның ике ягы да, Ә.Терегулов урамындагы 14 номерлы йорт янында һәм 18 номерлы йорт буйлап) | 50 | «Бала-Сити» халыкара полилингваль балалар бакчасы |